**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең 1 өлеше Зур Лызи авылында**
**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«18» ноябрь, 2020 ел. №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23нче маддәсе нигезендә Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең 1нче өлешендәге торак пунктында гражданнар җыены карар итте.

1. Балтач районы Кече Лызи авыл җирлегенең 1 өлеше Зур Лызи авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 2021 елда, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы һәм тыл ветераннарыннан, ялгыз карт гражданнардан, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 400 сум күләмендә үзсалым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

-Яңа урам буенча янгынга каршы гидрант урнаштыру, янгынга каршы колонка һәм аларга комплектлау әйберләре сатып алу;

- Голубев урамындагы юлларны норматив хәлгә китерү.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка игълан итәргә baltasi.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.

4. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл җирлеге башлыгы С. А. Мухин